ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№_284___ «_14_»___03_________2017 ел

2017 елның 1 кварталына гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче граждан кеременең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексы, Татарстан Республикасының 2007 ел, 13 июль, 31 ТРЗ “Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турындагы” законы, төзелеш, архитектура һәм торак коммуналь хуҗалык минстрлыгының ы Приказы буенча, Россия Федерациясе төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык минстрлыгының “ 2017 елның 1 кварталында Россия Федерациясе субъектлары буенча 1 кв. метрның уртача базар күрсәткечләре турында” 22.12.2018 ел, 1003/пр санлы боерыгы, , бер гражданга туры килә торган керемнең яисә ялгыз яшәүче граждан һәм гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасына таянып, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. 2017 елның I кварталына гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен иң чик күрсәткечләрне 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә:

1.1. Һәр гражданга туры килә торган керем күләме һәм гражданнар милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы кеременең иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче кеше өчен - 1 157 607 сум;
1.1.2. ике кешелек гаилә өчен - 1 473 318 сум;
1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 1 894 266 сум;
1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен - 2 525 688 сум;
1.1.5. биш кешелек гаилә өчен - 3 157 110 сум;
1.1.6. алты кешелек гаилә өчен - 3 788 532 сум;
1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен - 4 419 954 сум;
1.1.8. сигез кешелек гаилә өчен - 5 051 376 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче кеше өчен – 12045,84 сум;

1.2.2. ике кешелек гаилә өчен – 7697,62 сум;

1.2.3. Өч яки аннан да күбрәк кешелек гаилә өчен – 6597,96 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе ярдәмчесе Р. К. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И. Э. Фәттахов

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының
14.03.2017 ел, 284 нче номерлы
карарына
кушымта №1

2017 елның1 кварталына гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче
гражданга туры килә
торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан
милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының
иң чик күләмен билгеләү
МЕТОДИКАСЫI

1. Торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алуга базар хакының исәпләнгән күрсәткече (алга таба - исәп күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

СЖ = НП х РС х РЦ, монда:

СЖ - килешү буенча социаль найм торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ – 2017 ел, 1 кварталга бер квадрат метр торак урыны мәйданының әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган уртача исәпләнгән базар бәясе,

| НП, кв. м | РС, чел. | РЦ за 1 кв. м, руб. | СЖ, руб. |
|---|---|---|---|
| 33 | 1 | 35079 | 1 157 607 |
| 42 | 2 | 35079 | 1 473 318 |
| 18 | 3 | 35079 | 1 894 266 |
| 18 | 4 | 35079 | 2 525 688 |
| 18 | 5 | 35079 | 3 157 110 |
| 18 | 6 | 35079 | 3 788 532 |
| 18 | 7 | 35079 | 4 419 954 |
| 18 | 8 | 35079 | 5 051 376 |

2. Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган иң чик уртача айлык җыелма керем түбәндәгечә билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС/(1-(1+ПС)-КП)/(0,3 х РС), монда:

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү хакы буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме;

СЖ - килешү буенча социаль найм торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы (унарлы вакланма), (ачык чыганаклардан коммерцияле кредит оешмалары мәгълүматы буенча) 12 % елга, ягъни 12.8/12/ аена = 1.07 аена);

КП - кредитның барлык чорында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир хакының нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең һәм гаиләнең айлык җыелма кеременең нисбәте;

| кредит суммасының һәм фатир хакының нисбәте | СЖ, руб. | ПС | КП, ай. | кредит буенча түләүнең һәм гаиләнең айлык җыелма кеременең нисбәте | РС, кеше. | ПД, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 0,7 | 1 157 607 | 1,07 | 240 | 0,3 | 1 | 12045,84 |
| 0,7 | 1 473 318 | 1,07 | 240 | 0,3 | 2 | 7697,62 |
| 0,7 | 1 894 266 | 1,07 | 240 | 0,3 | 3 | 6597,96 |

Башкарма комитеты җитәкчесе
ярдәмчесе Р. К. Мөхәммәтҗанов